| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.05.2022 ел Баулы шәһәре №89

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булмаган гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2019 елның 3 июлендәге карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булмаган гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2019 елның 3 июлендәге карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән» сүзләрен преамбулада төшереп калдырырга;

Административ регламентта (карарга кушымта):

2нче «муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.5. пунктның икенче баганасында:

3) пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) гражданинда авырулар булмау турында дәвалау-профилактика медицина оешмасы белешмәсе (медицина бәяләмәсе) (әлеге Регламентка 3 нче кушымта);

3нче бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтәге эш урыннарында административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре»;

3.6.2. пунктының б) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) гражданин белән бергә яшәүче аның гаилә әгъзаларының ачык формада йогышлы авырулары һәм психик авырулары булмау турында дәвалау-профилактика медицина оешмасының белешмәсе. Белешмә урынына гражданинның гаилә әгъзалары дәвалау-профилактика медицина оешмасына бирелгән медицина бәяләмәсен тәкъдим итә алалар. Әлеге документлар опека һәм попечительлек бүлеге тарафыннан бирелгән көннән алып 6 ай эчендә кабул ителә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://www.pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында. http://www.bavly.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гузаиров